Важашур авыл башкарма комитеты

Карар

21 май, 2024 ел №9

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 23 сентябрендәге 15 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек объектларына адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Кукмара районы прокуроры вазыйфаларын башкаручының 29.03.2024 елның 29 мартындагы 02-08-01/2024 номерлы протестын карап чыгып, Важашур авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 23 сентябрендәге 15 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек объектларына адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (2021 елның 23 ноябрендәге 17 номерлы, 2022 елның 24 июнендәге 6 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктның унынчы абзацында «Әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән» сүзләрен «Гариза белән» сүзләренә алыштырырга»;

1.2. 2.3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.2 Адресация объектының адресын юкка чыгару турында карар, адресация объектына яңа адресны бирү очрагында, әлеге адресация объектына яңа адрес бирү турында карар белән берләштерелә.»;

1.3. 2.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты:

а) кәгазьдә гариза биргән очракта – гариза килгән көннән алып күп дигәндә 10 эш көнендә;

б) электрон документ рәвешендә гариза биргән очракта – гариза килгән көннән алып күп дигәндә 5 эш көнендә.

Муниципаль хезмәтне алдан (актив) режимда күрсәтү очрагында – Регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгән көннән башлап 3 эш көне.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты гаризаны теркәгәннән соң икенче көнне исәпләнә башлый.»;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы П.Л.Иванов